ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ГОРОДА ИННОПОЛИС
ул. Спортивная, д.114, г.Иннополис, Верхнеуслонский район, Республика Татарстан, 420500

ИННОПОЛИС ШӘҺӘРЕНЕҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Спортивная ур., 114-нче йорт, Иннополис шәһәре, Югары Ослан районы, Татарстан Республикасы, 420500

тел. (843) 212-27-24, e-mail: city@innopolis.ru, www.verhniy-uslon.tatarstan.ru/rus/innopolis.htm

ПОСТАНОВЛЕНИЕ 07.09.2023 | Иннополис шәһәре | КАРАР № 79

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турында нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 6 декабрендәге 47 номерлы Иннополис шәһәре Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Конституциясе, «Оборона турында» 1996 елның 31 маендагы 61-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә мобилизацион әзерлек һәм мобилизация турында» 1997 елның 26 февралендәге 31-ФЗ номерлы, «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 1998 елның 28 мартындагы 53-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар, «Хәрби исәпкә алу турында нигезләмәне раслау хакында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 27 ноябрендәге 719 номерлы карары, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Иннополис шәһәре Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турында нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 6 декабрендәге 47 номерлы Иннополис шәһәре Башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. I бүлекнең 1.2 пунктындагы е) пунктчасында «27 яшь» сүзләрен «30 яшь» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://verhniy-usLon.tatarstan.ru/ һәм Иннополис шәһәре Мэриясе бинасында урнашкан мәгълүмати стендта халыкка хәбәр ителергә тиеш.

3. Башкаруны тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче И.Р. Хуззятов